РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» 03 2026 ел №269

Гражданнар кеременең һәм
2026 елга салым салынырга
тиешле мөлкәт хакының максималь
күләмен билгеләү турында

"Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында"гы 16.03.2015 ел, №13-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. «2026 елның I кварталына Ютазы муниципаль районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен раслау турында»гы 2026 елның 04 февралендәге 93 санлы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының Карары нигезендә, гражданнар кеременең максималь күләмен исәпләү өчен, 2026 елга Ютазы районы буенча торак мәйданының 1 квадрат метрының уртача базар бәясен – 53 571 сум күләмендә расларга.

2. Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь бәясен әлеге карарга кушымта нигезендә расларга.

3. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы урынбасарына гражданнарны торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә куйганда әлеге карарга кушымтада күрсәтелгән керемнең максималь күләмен файдаланырга.

4. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле

үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина

С.Р. Сәетгәрәева
2-42-05

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитетының
«_12_»__03_2026 ел №269
Карарына кушымта

**Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган максималь керем күләме һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм 2026 елга салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе**

| Гаилә әгъзалары саны | Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәтнең максималь бәясе | Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләм |
|---|---|---|
| 1 | 964278 | 24524,02 |
| 2 | 1928556 | 24524,41 |
| 3 | 2892834 | 24524,54 |
| 4 | 3857112 | 24524,61 |
| 5 | 4821390 | 24524,65 |
| 6 | 5785668 | 24524,67 |
| 7 | 6749946 | 24524,69 |
| 8 | 7714224 | 24524,71 |
| 9 | 8678502 | 24524,72 |
| 10 | 9642780 | 24524,73 |